ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 172-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 172-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 15 апреле
№ 620-VII ДС

172-7 номерлы проект
Татарстан
Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2025, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге $10^1$ пунктны өстәргә:
«$10^1$) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен раслау тәртибен билгеләү;»
2) 4 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге $9^9$ һәм $9^{10}$ пунктларны өстәргә:
«$9^9$) ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен раслау;
$9^{10}$) региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына карата «Торак өлкәсендә идарә итүне үстерүгә һәм аның нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 225-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына белешмәләр кертү;»

3) 14 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында «шул исәптән мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зонасын» сүзләрен «шул исәптән мәдәни мирас объектларының бердәй саклау зонасын, төзелеш һәм хуҗалык эшчәнлеген җайга салуның бердәй зонасын һәм саклана торган табигать ландшафтының бердәй зонасын (алга таба - мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зонасын)» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының өченче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының өченче абзацы 2026 елның 1 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

Закон проекты «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 60-ТРЗ номерлы Закон) нигезләмәләренең федераль законнарга туры килүен тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында» Федераль законга һәм «Торак өлкәсендә идарә итүне үстерүгә һәм аның нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 2 һәм $5^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 17 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә өстәмә вәкаләтләр бирү өлкәсендә үзгәрешләр кертелгән.

Күрсәтелгән органнарның вәкаләтләренә 2026 елның 1 июненнән региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына карата «Торак өлкәсендә идарә итүне үстерүгә һәм аның нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 225-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына белешмәләр кертү кертелде. Закон проектында 60-ТРЗ номерлы Законына төзәтмә рәвешендәге үзгәрешләр кертү карала.

Моннан тыш, «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 31 статьясы белән ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләре Россия Федерациясе субъектының мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә вәкаләтле башкарма органы акты белән Россия Федерациясе субъекты законнарында билгеләнгән тәртиптә раслана дип билгеләнгән.

Федераль законның 34 статьясы нигезендә «мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зонасы» термины «мәдәни мирас объектларының бердәй саклау зонасы, төзелеш һәм хуҗалык эшчәнлеген җайга салуның бердәй зонасы һәм саклана торган табигать ландшафтының бердәй зонасы» төшенчәсенең кыскартылмасы булып тора. Закон проектында 60-ТРЗ номерлы Законына тиешле төгәлләштерү кертү карала.

«Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты Хокук мәсьәләләре буенча ведомствоара координация комитеты тарафыннан каралган һәм хупланган (2026 елның 31 мартындагы 2 нче номерлы Беркетмә).

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы карарына үзгәрешләр кертүне, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен раслау тәртибен билгеләү турында карар чыгаруын таләп итә.

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.